МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 67/о

"25" 06 2019

БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 апрелендәге 79/о номерлы, 2017 елның 05 сентябрендәге 155/о номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге 226/о номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге 63/о номерлы, 2018 елның 9 октябрендәге 167/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы мөдире Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының 2019 елның
«25» 06 № 67/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.3.2 пунктчаның дүртенче абзацында «(http://uslugi.tatar.ru/);» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru);» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктның унөченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт экспертизасы уздыру вакытының максималь озынлыгы шартнамәдә билгеләнә, объектның катлаулылык дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнә, ләкин 21 эш көненнән артып китәргә тиеш түгел. Төзүче оешма яки техник заказчы гаризасы нигезендә срок егерме эш көненнән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.

Бәяләмә дубликатын тапшыру түләүсез нигездә язмача мөрәҗәгать алынган датадан соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада тапшырылган документларда документларны дәүләт экспертизасына кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпче булган җитешсезлекләрне бетерү мөмкинлеге булганда «ТР ДЭБХИ» ДАУ мондый җитешсезлекләрне бетерү өчен ун эш көненнән артмаска тиешле срок билгели.»;

сигезенче-тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «шулай ук тәкъдим ителергә (җибәрелергә) мөмкин» сүзләрен «тапшырыла» сүзенә алмаштырырга;

унберенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының «а» пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«а) проект документлары составында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләр нигезендә мондый документация составына кертелергә тиешле бүлекләрнең булмавы;»;

3.5 пунктта:

өченче-дүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

бишенче абзацта «, шул исәптән электрон формада тапшырылган» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7.2 пунктчаның икенче-өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитешсезлекләрне бетерү вакыты мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алганнан соң биш эш көненнән дә артмый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар шартнамә имзаланган һәм дәүләт экспертизасын үткәрү өчен түләү кертелгән вакыттан башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.7.3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе өчен сәбәпче булган җитешсезлекләрне өстәмә эшләп бетергәннчән соң Мөрәҗәгать итүче кертелгән үзгәрешләре белән проект документациясенең һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең бер өлешен һәм шушы үзгәрешләрне тасвирлаган белешмәне (кисәтүләргә җавапларны) «ТР ДЭБХИ» ДАУ тапшыра.

3.8.1 пунктчаның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар җитешсезлекләре бетерелгән үзгәртелгән документация Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган вакыттан алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.8.1[1] пунктча белән тулыландырырга:

«3.8.1[1]. Проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлегенең вәкаләтле хезмәткәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе расланган көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүче тапшырган бәяләмәне һәм документларны экспертиза уздыру өчен Капиталь төзелеш объектларының проект документларына экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына (алга таба – БДБР ДМС) кертә.

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе турында белешмәләрне БДБР ДМС кертү, дәүләт экспертизасы бәяләмәсен БДБР ДМС теркәү (дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номеры бирү) мәгълүмат системасы («Баш дәүләт экспертизасы идарәсе» федераль автоном учреждениесе – алга таба «Главгосэкспертиза России» ФАУ) операторы тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларны БДБР ДМС керткән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Тапшырылган документларда «Главгосэкспертиза России» ФАУ тарафыннан дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номерын беркетү һәм мондый бәяләмә турында белешмәләрне БДБР ДМС кертү мөмкинлеген бирми торган җитешсезлекләр ачыкланган очракта, проектлар белән эшләү һәм бәяләмәләр бирү бүлеге хезмәткәре мәгълүмат системасы операторыннан баш тарту алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә тиешле кисәтүләрне бетерә, шулай ук БДБР ДМС документларның билгеләнгән комплектын яңадан тапшыруны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар бәяләмә «ТР ДЭБХИ» ДАУ тарафыннан расланган вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт экспертизасы бәяләмәсе турында мәгълүматларны БДБР ДМС кертү, дәүләт экспертизасы бәяләмәсен БДБР ДМС теркәү (дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә реестр номеры бирү).»;

3.8.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.2. Электрон документ формасындагы дәүләт экспертизасы бәяләмәсе, БДБР ДМСта реестр номеры бирелгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча, ләкин дәүләт экспертизасын уздыру срогының соңгы эш көне узганчы, Мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына кертелә.

Әгәр Заказчы гаризасында каралган булса, бәяләмә шулай ук кәгазь документ формасында да бирелә.

Кәгазь саклагычта бәяләмә Мөрәҗәгать итүченең кулына яисә аның ышанычлы затына тапшырыла, яисә хәбәрләмәле заказлы хат итеп җибәрелә.

Дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе дүрт нөсхәдә бирелә. Тискәре бәяләмә – бер нөсхәдә.

Бәяләмәне алу өчен Мөрәҗәгать итүче «ТР ДЭБХИ» ДАУ шәхесен таныклаучы документны, Мөрәҗәгать итүченең вәкиле юридик затның законлы вәкиле тарафыннан таныкланган ышанычнамәне һәм шәхесен таныклаучы документны күрсәтергә тиеш.

Проект документлары, проектлауга бирем күчермәсе, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм электрон формада тәкъдим ителгән инженерлык эзләнүләрен башкаруга биремнәр күчермәсе кире кайтарылырга тиеш түгел.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт экспертизасы бәяләмәсе БДБР ДМС теркәлгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Теркәлгән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен Мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына кертү яки Мөрәҗәгать итүчегә тапшыру.»;

3.9 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.12 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3.12. Проект документациясе һәм (яисә) инженерия эзләнүләре нәтиҗәләре тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә күрсәтелгән җитешсезлекләре бетерелгәннән соң яисә уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документациясенә капиталь төзелеш объектының конструктив һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына тия торган техник

чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгәндә дәүләт экспертизасына яңадан (ике һәм аннан артыграк мәртәбә) җибәрелә.

Уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документациясе, төзүченең яисә техник заказчының инициативасы белән, аңа капиталь төзелеш объектының конструктив һәм куркынычсызлык буенча башка сыйфатламаларына тими торган техник чишелешләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракта дәүләт экспертизасына яңадан (ике һәм аннан артыграк мәртәбә) җибәрелергә мөмкин.

Транспорт инфраструктурасының линияле объектларына карата әзерләнгән һәм уңай дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә транспорт инфраструктурасы линияле объектлары кишәрлекләренә һәм (яисә) конструктив элементларына һәм (яисә) юл корылмаларына карата капиталь төзелеш объектының конструктив һәм куркынычсызлык сыйфатламаларына тия торган үзгәрешләр кертелгән очракта, кабат уздырылучы дәүләт экспертизасына проект документациясенең күрсәтелгән өлешләр кертелгән өлеше генә, шулай ук инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре тулы күләмендә тапшырыла.

Яңадан дәүләт экспертизасын үткәрү Нигезләмәдә беренче дәүләт экспертизасын үткәрү өчен каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Тискәре дәүләт экспертизасы бәяләмәсе өчен сәбәпче булган җитешсезлекләрне өстәмә эшләп бетергәннчән соң Мөрәҗәгать итүче кертелгән үзгәрешләре белән проект документациясенең һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең бер өлешен һәм шушы үзгәрешләрне тасвирлаган белешмәне (кисәтүләргә җавапларны) дәүләт экспертизасын уздыручы оешмага тапшыра.»;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.12[1] пункт өстәргә:

«3.12[1]. Дәүләт экспертизасы бәяләмәсен югалткан очракта, мөрәҗәгать итүче «ТР ДЭБХИ» ДАУ бу бәяләмәнең дубликатын алырга хокуклы. Дубликат тапшыру түләүсез нигездә язмача мөрәҗәгать алынган датадан соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

5.1 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР ДЭБХИ» ДАУ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр хезмәт күрсәтелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына тапшырыла, дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына яки монополиягә каршы органга бирелә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада «30 эш көненнән артмый» сүзләрен «21 эш көненнән артмый» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нче кушымтада:

2.2 пунктчада «18%лы ставка буенча НДС» сүзләрен «20%лы ставка буенча НДС» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктчада «30 эш көне» сүзләрен «21 эш көне» сүзләренә

алмаштырырга;

4.4.5 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

шартнамәнең 1 нче кушымтасында «18%лы НДС» сүзләрен «20%лы НДС» сүзләренә алмаштырырга;

шартнамәнең 2 нче кушымтасында «18%лы НДС» сүзләрен «20%лы НДС» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 4 нче кушымтада «Төп белешмәләр исемлеге:» сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга: «Кәгазь документ формасында бирү __________.

Әйе/Юк »;

Регламентка 8 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.